**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 8 апрель № 207

г. Казань

Татарстан Республикасының аерым дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләрен бетерү турында

«2 нче республика клиник хастаханәсе», Казан шәһәренең «2 нче ашыгыч медицина ярдәме шәһәр хастаханәсе», Казан шәһәренең «2 нче шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләренең җир-мөлкәт комплексын түләүсез файдалануга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белемнең федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә медико-санитар часть төзү өчен тапшыру, шулай ук әлеге дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләрен 2016 елда мәҗбүри медицина иминиятләве өлкәсендә эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы медицина оешмалары реестрыннан чыгару белән бәйле Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «2 нче республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (алга таба – 2 нче республика клиник хастаханәсе), Казан шәһәренең «2 нче ашыгыч медицина ярдәме шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (алга таба – 2 нче ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе), Казан шәһәренең «2 нче шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (алга таба – 2 нче поликлиника) гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 420043, Татарстан Республикасы, Казан ш., Чехов ур., 1а йорты адресы буенча урнашкан 2 нче республика клиник хастаханәсен, 420061, Татарстан Республикасы, Казан ш., Н.Ершов ур., 2 йорт адресы буенча урнашкан 2 нче ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсен, 420097, Татарстан Республикасы, Казан ш., Вишневский ур., 2а йорты адресы буенча урнашкан 2 нче поликлиниканы бетерү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

14 көн эчендә:

2 нче республика клиник хастаханәсен, 2 нче ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсен һәм 2 нче поликлиниканы бетерү комиссияләре составын расларга;

Россия Федерациясе Гражданнар кодексы нигезендә 2 нче республика клиник хастаханәсен, 2 нче ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсен һәм 2 нче поликлиниканы

бетерү тәртибен һәм вакытларын билгеләргә;

2 нче республика клиник хастаханәсен, 2 нче ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсен һәм 2 нче поликлиниканы бетерү турында карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә 2 нче республика клиник хастаханәсе, 2 нче ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе һәм 2 нче поликлиника бетү процессында булу хакында белешмәләрне Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен теркәүче органга тапшырырга;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә бетерү нәтиҗәсендә эштән чыгарылучы хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә, шулай ук 2 нче республика клиник хастаханәсен, 2 нче ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсен һәм 2 нче поликлиниканы бетерү буенча законнарда каралган бүтән чараларны гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков